وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт


6+

№14 (157). 5 октябрь 2012 / 19-зөлкагдә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Үз-үзегезне үтермәгез! ▷2◁



Хаҗ кылуларым – Аллаһ рәхмәте, дөнья-ахирәт гыйбрәте ▷3◁



Дин кушканча яшәргә телим, тик әйләнә-тирәмдәгеләр моны кабул итми... ▷4◁

## Укытучылар көне белән!

**Хөрмәтле мөгаллимнәр! Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән һөнәри бәйрәмегез - Укытучылар көне белән котлыйм!**

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Аллаһы Тәгалә, фәрештәләр, җир һәм күк ияләре - хәтта кырмыскалар һәм судагы балыклар да укытучыларга игелек кылуда фатиха бирәләр", - ди. Укытучы һөнәре ислам динендә бик югары бәяләнә.**



Шулай ук: "Арагыздан иң яхшысы - белем алып, аны башкаларга тараткан кеше", - диелә. Башка бер хәдисендә Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв): "Укытучыгыз сезгә әтиегез кебек", - ди. Имам Суфьян әс-Сәүри болай дигән: "Мин кешеләргә белем бирүдән дә зур гыйбадәтне белмим". Мөгаллимлек итү дәрәҗәсе ислам динендә шулкадәр зур!


Укытучы - кешелекнең гасырлар буе туплаган белемен безгә җиткерүче кеше. Зур ихтыяр көче, сабырлык сорый торган мөгаллимлек сәләте һәр кешегә дә бирелми. Гыйлем җиткерү Аллаһы Тәгалә һәм җәмгыять алдында зур җаваплылык. Җәмгыятьнең киләчәге хәзерге укытучылар хезмәтеннән күзаллана. Шуңа күрә укытучыларның абруе һәрвакыт югары.

Хөрмәтле укытучылар! Аллаһы Тәгалә гыйлем ияләре буларак сезнең дәрәҗәгезне югары күтәрә. Белемнәрегезне ихлас күңелдән яшь буынга җиткереп, аларның игелеген, хезмәтегезнең әҗер-савабын күрергә язсын!

*Үзәкләшкән дини оешма –*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

## ӘЛ-МАТУРИДИ ТӘГЪЛИМАТЫ ТАТАРЛАРГА НИЧЕК ҮТЕП КЕРГӘН?

**Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) билгеле бер хәдисендә бервакыт Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) һәм аның сәхабәләренә бәдәви кыяфәтенә кереп Җәбраил фәрештә килүе һәм Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) каршына утырып, аңа сораулар бирә башлаганы турында сөйләнә. Аның иң мөһим сорауларыннан "Ислам нәрсә була ул?", "Иман нәрсә була?" һәм "Ихсан нәрсә буладыр?" сораулары булган. Бу сораулар Ислам гыйлеменең өч төп фәне - фикъһе, гакыйдә һәм тәсаувүфнең нигезләрен салганнар.**



**ГАКЫЙДӘ** - иман төшенчәсен, ягъни, инкыйлабка кадәрге татар китапларында искә алынган аның шул алты баганасын өйрәнә торган фән.

**"Әәмәнтү билләәһи үә мәләәикәтиһи үә күтүбиһи үә русүлиһи үәл йәүмил әәхыйри, үәл кадәри шәрриһи үә хайриһи минәллаһи тәгаләә үәл бәгъси бәгъдәл мәүти"**. *(Мәгънәсе: "Мин Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына, Пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә, Тәкъдирнең яхшысы-яманы да Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә һәм үлгәннән соң янә терелүгә иман китердем").*

Соңгы багана Кыямәт көне вакыйгаларының берсе һәм шуның өчен без иманның алты баганасы турында сөйлибез дә. Бу фән шуны өйрәнә дә инде.

Гакыйдәнең, фикъһе кебек үк, шәригать гыйлеменең иң төп һәм иң мөһим фәннәренең берсе икәнен әйтеп китәргә кирәк. Ләкин шул ук вакытта болар - саф теоретик фәннәр. Шуңа да, мөэмингә камиллеккә ирешү өчен бу фәннәрнең рухи якларына зур әһәмият бирергә кирәк. Бу өлкәне я әхлак, я тәсаувүф, я селүк дип атала торган мөселман этикасы ачыклап килә. Ләкин этиканың ничек итеп гыйбадәт кылырга, ничек тәгам кабул итәргә кебек өлешен генә түгел, ә бәлки, бу фәннең инсан белән аны Бар итүче арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, ихласлык, рәхимшәфкатьлелек, нәфескә каршы тору һ. б. яклар да өйрәнелә. Инсан менә шул алда искә алынган өч фәнне үзендә берләштерә алганда гына чын иманлы була ала.

### Ислам фәннәренең килеп чыгышы һәм барлыкка килү тарихы

Билгеле булганча, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәләм заманнарында безгә билгеле булган Ислам фәннәренең берсе дә булмаган. Әлеге барлык фәннәрне дә без бик кыю рәвештә яңалык кертү (бидгать) дип атый алабыз. Шәригать буенча, яңалык кертүләрнең ике төре була: рөхсәт ителгәннәре һәм тыелганнары. Бу фәннәр безгә динне өйрәнүне нык җиңеләйткәнгә, аларны хуплана торган яңалык исемлегенә кертә алабыз.

Нәкъ шушы вакытта сорау да туа инде: "Ни өчен Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) заманында алар булмаганнар соң?" Җавап бик гади: "Аларның зарурлыгы булмаган". Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) теләсә кайсы замандашы килеп туган мәсьәлә буенча теләсә нинди сорауны аңа килеп сорый алган. Тиешле җавапны алгач, ул Аллаһ канунары буенча тормыш итүен дәвам иткән. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бу

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**СУД "НЕВИННОСТЬ МУСУЛЬМАН" ФИЛЬМЫН ЭКСТРЕМИСТИК БУЛАРАК ТАНЫДЫ**

**Мәскәү шәһәренең Тверь районы суды Мәскәү прокуратурасы дәгъвасы буенча "Невинность мусульман" фильмын экстремистик буларак таныды һәм аны Россиядә күрсәтүне тыйды, дип хәбәр итә "РИА Новости" мәгълүмат агентлыгы.**

Судья Евгений Комиссаров сүзләренә караганда, суд карары белән канәгать булмаганнарның апелляция бирергә мөмкинлекләре бар. Фильмны тыю сәбәпләре бүген - 5 октябрь көнне игълан ителәчәк.

Генераль прокуратурага фильмны күрсәтүне тыюны сорап, судка мөрәҗәгать итүгә берничә төбәктә аны карауга чикләүләр куела. Төньяк Кавказ республикаларының кайберләрендә "YouTube" видеохостингына керүне чиклиләр.

Шунысын да билгеләп узарга кирәк, "YouTube" хуҗасы булган "Google" компаниясе суд карарын үтәп, Россиядә бу фильмны карау мөмкинлеген бетерәчәге турында белдерде.

**ТАТАР ТЕЛЕ, ИСЛАМ ДИНЕ НИГЕЗЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАР ХАЛКЫ ТАРИХЫ БУЕНЧА КУРСЛАР ОЕШТЫРЫЛА**

**Россия ислам университеты Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән берлектә татар телен тиз арада өйрәнергә, ислам дине нигезләре һәм татар халкы тарихын үзләштерергә теләүчеләрне курсларга чакыра. Укыту "Без - татарлар" дигән проект нигезендә оештырыла. Уку түләүсез.**

Дәрес бирү сәгатьләре көн дә кичен була. Укып бетергәч, теләгәннәр сертификатлы була алачак. Белешмәләр өчен телефон: ***89503200935, 89274221751, 8(843)2537163.***

**ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ ЕГЕТЛӘРНЕ АРМИЯГӘ ОЗАТА**

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Татарстан Хәрби комиссариаты белән хезмәттәшлек итә. Ислам дине вәкилләре җомга көнне ТР Җыелу пунктына барып, армиягә китәргә җыенучылар белән очраша, аларга үгет-нәсыйхәт бирә, вәгазьләр укый, хәрби хезмәткә китүчеләрне ислам дине нигезләре белән таныштыра.**

Айрат хәзрәт Зарипов хәбәр иткәнчә, яшьләр белән эшләүне алар комиссия үтеп йөргән вакытта ук башлап җибәрергә, шулай итеп, эшне күпкә җәелдерергә дигән фикер дә бар.

Ислам дине вәкилләре яшьләрне армиягә җибәрү эшелоннарын озата бару белән дә шөгыльләнә.

Айрат хәзрәткә армиягә үзе теләп киткән дин тотучы егетләр белән дә аралашырга туры килгән. Алар армиядә бернинди дә чикләүләр булмаганлыгын, намазларны вакытында укуларын, туклану мәсьәләсендә дә кыенлыклар килеп тумавы турында хәбәр иткән.

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# Үз-үзегезне үтермәгез!

**Бүгенге көндә еш кына үз-үзләренә кул салучы кешеләр турында ишетергә туры килә. Дөньяда 40 секунд саен бер кеше үз-үзен үтерә. Елына дөнья буенча бер миллион суицид очрагы теркәлә. Балалар суициды очраклары буенча Россия Европада беренче, ә дөньяда - бишенче урында. Бу хәл уйланырга мәҗбүр итә.**



Элек үз-үзләренә кул салу очраклары күбесенчә шәһәрләрдә генә булса, хәзер бу күренеш авыл җирлегенә дә күчте. Бу бәла безнең якларга да килеп җитте - Чирмешән районында суицид очраклары ешайды. Суицид очраклары дистәләп очрамаса да, социаль яктан уңышлы саналган районыбыз өчен 2-3 суицид та зур проблема булып тора. Һәм бу проблеманы чишәргә кирәк, читтән карап торырга гына түгел, ә җиң сызганып эшкә тотынырга.

Күбесенчә үз-үзенә кул салучылар - яшәүнең мәгънәсен аңламаган, тормышта үз урыннарын тапмаган кешеләр. Күпләр бу дөньяны камил түгел дип уйлап, аның белән хушлашырга әзер. Алар: "Аллаһы Тәгалә дөньяны камил итеп яраткмаганмыни? Ни өчен бу дөньяда үтерүләр, көчләүләр, проблемалар күп? Ни өчен гармония һәм татулык юк? Дөнья камил түгел икән, димәк Аллаһы Тәгалә дә юк", - диләр. Аларның сорауларына җавап итеп, түбәндәгене әйтәсе килә: мондый кешеләр бу дөньяның мәгънәсен дөрес аңламыйлар. Алар Аллаһы Тәгаләдән камил ләззәтне өмет итәләр. Ләкин мондый функция өчен Ул Җәннәтне булдырган, ә бу дөньяның функциясе - сынау. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Бөтен хөкемдарлыкны хозурында тотучы Аллаһ олугларның бөегедер вә Аллаһның көче бөтен нәрсәгә җитә. Аллаһ кемнең игелек кылачагын сынап карар өчен, үлемне, яшәеш тормышны бар итте. Аллаһ - җиңү белмәс кодрәт иясе, чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучы" ("Мөлек (Падишалык)" сүрәсенең 1-2 нче аятьләре).

Җәмгыятьтәге суицидлык күренешләре белән ничек көрәшергә соң? Бу сорауга җавап бик җиңел дә, шул ук вакытта бик катлаулы да.

Беренчедән, кешеләргә тормыштан бу юл белән китүнең куркынычлыгын аңлатырга кирәк. Барлык диннәрдә дә төгәл әйтелә: "Үзүзеңә кул салу гафу ителми". Коръәни-Кәримдә бу темага бик акыллы сүз бар: "<...> Үз кулларыгыз белән үзегезне куркыныч һәлакәткә ташламагыз <...>" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 195 нче аяте).

Бу сүзләрдә Аллаһы Тәгалә кешеләрнең үз-үзләрен үтерүләрен тыюы ачык күренә. Тормышның өзелүенә китерә торган үз-үзеңне тотышны психологлар "яшерен суицид" дип атый. Моңа кешенең тиз арада үлеменә китерми торган, ләкин тормышыңа куркыныч янаган үз-үзеңне тотыш керә: эчкечелек, тәмәке тарту, каты авыру вакытында табиблар ярдәменнән баш тарту, юл йөрү кагыйдәләрен бозу, техника белән эш иткәндә саклык чараларын күрмәү һ. б. Боларның барысы да Коръәндә тыелган, чөнки яшәү - Аллаһы Тәгалә бүләге һәм Ул гына аны өзә ала.

Икенчедән, бу аңлатмага күп кеше колак салмый. Алар, Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйча, мондый адымнарга баралар икән, димәк, динсезлек тәэсире күпләрдә калган, күрәсең.

Шуңа да җәмгыятьтә суицидлык белән көрәшү җиңел эш түгел, кеше тормыштагы, гаиләдәге авырлыкларга түзеп тора алмыйча, шайтан котыртуына бирелеп, газаплардан котылачакмын дип уйлап, үз-үзенә кул сала. Ләкин киресенчә, тормыш авырлыклары урынына куркынычрак газаплар килә. Пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв): "Кыядан сикереп, үз-үзен үтергән кеше - мәңгелек җәһәннәмгә сикерә; агу эчеп үз-үзен үтергән кеше - кулына агу тотып, мәңге җәһәннәмдә яначак; үз-үзен корал белән үтергән кеше - шул ук корал белән мәңгелек җәһәннәмдә үз-үзен җәфалаячак", - дигән. Үз-үзен үтергән кешенең туганнары да күңелләренә авыр йөк алалар, чөнки ислам һәм христиан диннәре буенча андый кешене бар кеше дә җирләнә торган зиратка күмү рөхсәт ителми, үлем-китем йолаларын үткәрү дә аңа "булышмый".

***Хәбир хәзрәт ХАНОВ,***
***Чирмешән Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы***

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

# Коръән уку әдәбе

1. Беренчедән, Коръәнне дөньяда нинди дер шөһрәткә омтылу яки башка хирыслык белән түгел, ә Аллаһы Тәгалә өчен генә, Аның рәхмәтенә ирешү өчен, Аллаһка итагать итеп укырга кирәк.

2. Коръән китабын кулга алганда һәм дә укып бетергәч, кире урынына куйган вакытта, мөмкин булган кадәр артың белән борылмый урнаштырырга кирәк.

3. Тәһарәт алмый торып Коръән китабына кагылу тыела. Тәһарәтсез килеш Коръәнне яттан укырга рөхсәт, бу очракта да тәһарәтле булу - Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөннәте.

4. Шәригать кануннары буенча бар тәнне юу тиешле очракларда (җенси якынлык кылганнан соң һ. б.), һәм дә хатын кызга, аңа намаз укырга ярамаган вакытларда (айлык күрем вакытында, бала тапканнан соң килә торган күремнәр вакытында) Коръәнне уку гына түгел, хәтта яттан сөйләү дә тыела.

5. Коръәнне чиста урынга утырып, йөзне кыйблага юнәлдереп уку сөннәткә туры килә.

6. Коръән китабын идәнгә кую, гәрчә ул чиста булса да - Коръән уку әдәбен бозу. Берәр мендәргә яки аслыкка кую яхшырак, чөнки бу - сөннәт.

7. Коръән китабы битләрен бармакларны төкерекләп актару тыела.

8. Коръән китабы бар китаплардан да өстәрәк урнаштырылырга тиеш. Аның өстенә башка китаплар кую тыела.

9. Әгәр дә кем дә булса Коръән китабын, яки аять яки сүрә язылган берәр битне аңлы рәвештә пычракка ташлый икән, бу - кяферлек.

10. Бәдрәфкә яки башка шундый нәҗес урыннарга үзен түгел, хәтта Коръәннең аятьләре язылган кәгазьле битне алып бару яки анда аны кычкырып уку тыела.

11. Коръәнне укучы кыйблага карап утырып укыса - сөннәт. Коръәнне ятып укуда да гөнаһ юк.

12. Иң яхшысы - Коръәнне намаз вакытында уку.

13. Коръән укуны "Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим (Шайтанның явызлыгыннан Аллаһка сыенамын)" дип башлап, аннан соң "Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! (Рәхмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән (башлыймын)" сүзләрен әйтеп уку сөннәт санала.

14. Коръәнне мәчеттә яки төнлә уянып укучылар иң зур рәхмәткә ия булырлар.

15. Коръәнне, гәрчә аның мәгънәсе аңлашылмаса да, ашыкмыйча, тыныч кына уку яхшы.

16. Коръәнне укыган вакытта елау - сөннәт санала. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): " Коръән сагыш белән иңдерелде, аны укыган вакытта елагыз. Елый алмасагыз да, еларга тырышыгыз", -дигән.

17. Сәҗдә аятен (баш җиргә тигәнче иелү (баш ору) - сәҗдә кылу аятендә) укыгач, сәҗдәтиләвәт (сәҗдә кылу) вәҗип санала. Җәмәгать намазы укылганда, имамга оючылар да аны кылырга тиеш. Имам "Аллаһу әкбәр" дип тәкбир әйтеп сәҗдә кыла, аның артыннан башка намаз укучылар да шуны ук кабатлый. Аннан соң имам "Аллаһу әкбәр" дип торып баса, аның артыннан - башкалар да. Әгәр кем дә булса, бу вакытта намаз укымаса да, сәҗдә аятен укыганны ишетсә, аңа да сәҗдә кылу тиеш. Сәҗдә-тиләвәт кылучының гаурәтләре (намаз укыган вакытта шәригать буенча капланырга тиешле урыннар) капланган, һәм дә ул кыйблага таба караган булырга тиешле. Ул: "Мин сәҗдә-тиләвәт башкарырга ниятлимен", - дип ниятен эчтән әйтеп, "Аллаһу әкбәр" дип сәҗдә кыла. Аннан соң, тагын "Аллаһу әкбәр" дип әйтеп торып баса.

18. Коръән текстын Коръән китабыннан (мөсхәфтән) карап уку яхшырак. Монысы ныграк та бәяләнә, чөнки бу вакытта Аллаһка күзләребез аша табыну да бар.

*(Ахыры киләсе санда)*

# Башлангыч дини белем бирүче мөгаллимнәр Казанга җыелды

**4 октябрь көнне Россия ислам университетында мәчет каршындагы дини курсларда белем бирүче мөгаллимнәр республика киңәшмәсенә җыелды. Икенче тапкыр үткәрелгән киңәшмәне Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам университеты белән берлектә үткәрде. Чарага һәр мөхтәсибәттән башлангыч дини белем бирүчеләр чакырылган иде. Чарада йөз сиксәннән артык мөгаллим катнашты.**

Дини сабак бирүче мөгаллимнәр киңәшмәсен Татарстан мөфтие вазифаларын вакытлыча башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов ачып җибәрде һәм мөгаллимнәрне мөфти исеменнән сәламләде. Аннары Габдулла хәзрәт татар халкының дини мирасы, хәнәфи мәзһәбенең үзенчәлекләре турында вәгазь сөйләде.

Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы рәисе, РИУ проректоры Рөстәм хәзрәт Батыр үзенең чыгышында: "Мәчетләрдә эшләүче мөгаллимнәр Исламда иң зур, кирәкле эш алып бара, алар аркылы кешеләр дин юлына баса. Имамнарның эше күп һәм хезмәте зур. Имамга намаз укырга әзер кешеләр килә. Ә мөгаллимнәр янына намаз укымаган, диндә берни белмәгәннәр килә. Мөгаллимнәр аларны өйрәтә, намазга бастыра. Менә шулай итеп динебезне саклыйлар, рухи кыйммәтләрне халыкка җиткерәләр", - дип мөгаллимнәр хезмәтен югары бәяләде.

Бөтендөнья татар конгрессы рәисе урынбасары Ренат Вәлиуллин исә авылларда сабак укыту үзенчәлекләрен Арча районының Урта Сәрдә авылында дини башлангыч белем бирүне башлап җибәргән этиәнисе тәҗрибәсе аша сөйләп бирде: "Узган ел уздырылган киңәшмәнең җыентыгын карадым. Менә шунда Вәлиулла хәзрәтнең чыгышы урын алган. Һәм ул күтәргән мәсьәләләр бик тә әһәмиятле. Бүген безгә сабак алырга йөрүчеләрнең яшь үзенчәлекләрен истә тоткан программалар да булдыру мөһим".



Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Айдар Карибуллин республикада дини башлангыч белем бирү өчен бердәм укыту программалары барлыкка килүе турында әйтте. Алга таба да аларны камилләштерү өчен мөгаллимнәрне бергәләп эшләргә чакырды. "Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрдә укытулар алып барылуга зур игътибар бирә. Чөнки менә шушы курсларда башлангыч дин нигезләре өйрәтелә. Мәчетләр каршында оештырылган дәресләрдә балалар да, өлкәннәр дә укый. Республика күләмендә мөгаллимнәрне быел без Казанга икенче тапкыр җыйдык. Бу чара укытучылар өчен аралашу һәм проблемалар хакында бергә җыелып сөйләшү, киңәшү, тәҗрибә уртаклашу мәйданы булып тора. Узган ел киңәшмәдә берьеллык курслар өчен программалар тараткан идек. Быелгы очрашуга өчьеллык курслар өчен программаларны, шулай ук узган елгы киңәшмәнең җыентыгын әзерләдек, шулай ук Габдулла хәзрәт Әдһәмовның "Акыйда" китабын өләшәбез", - диде ул.

Киңәшмәдә күп еллар дәвамында дини башлангыч белем бирүче мөгаллимнәр үзләре дә чыгышлар ясады, тәкъдимнәрен җиткерде.

Арча районы мөхтәсибәте мөгаллимәсе Фәтхуллина Рая Ахун кызына динибез кыйммәтләрен таратуга, рухи тәрбия бирүгә зур өлеш керткәне өчен нәзарәтнең рәхмәт хаты тапшырылды.

# ХАҖ КЫЛУЛАРЫМ - АЛЛАҺ РӘХМӘТЕ, ДӨНЬЯ-АХИРӘТ ГЫЙБРӘТЕ

**Меңләгән дин әһелләребез, олуг галимнәребез, зыялыларыбыз, әти-әниләребез күпме хыялланып та мөмкин булмаган, рөхсәт ителмәгән хаҗ кылулар ничек иркенәйде хәзер! Согуд Гарәбстанына - Мәккә-Мәдинәгә юллар ачылды, фарыз гыйбадәтне кылу өчен шартлар да, бару-кайтулар да елдан-ел уңайлана. Бөтен юллар ачык: малы җиткән, саулыгы булган һәр кешегә фарыз булган хаҗ гыйбадәтен кылу өчен бернинди киртәләр, чикләүләр калмады дип шөкрана кылабыз. Бу хакта еш уйланам, үткәннәрне фикерләп, чагыштырып утырам.**

... 1993 ел. Ерак сәфәргә - хаҗ гыйбадәтенә кузгалырга планым да, рәтем дә юк иде әле. Шулай да күңелгә "корт" керде.

Күп тә үтми бер төркем мөселманнарыбыз ап-ак ихрамнарга кереп, хаҗга кузгалдылар. Аларны озаткач, иртүк мәчеткә килдем дә, намаз укып дога кылдым. Теләк теләдем. Я Раббым, озын, авыр сәфәргә китүче дин кардәшләребезгә җиңеллек бир, хаҗларын кабул кыл, дидем. Сәҗдәмдә киләчәктә үземә дә шушы фарыз гыйбадәтне үтәүне насыйп ит, дип сорадым. Ул елны кемнәр китүен тикшермәдем дә, күпсенмәдем дә. Фәкать Аллаһы Тәгаләдән үземә дә, китүчеләргә дә хәерлесен бир, дидем.

Икенче елны миллионнарча мөселманнар омтылган бу изге җирләргә аяк басуны насыйп итте Аллаһы Тәгалә. Беренче хаҗ! Андагы тәүге тәэсирләрне, күз яше катыш хис-кичерешләрне әйтеп аңлатып кына бетерерлекме соң?! Һәр күренеш - гыйбрәт, һәр адымың - сынау.

Танкодром бистәсендә Мәдинә мәчетебезне салып чыгып, эшләребезне матур гына алып баргач, бу юлдагы тырышлыкларым өчен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте 1998 елда миңа Согудия Короле кунагы сыйфатында бүләк хаҗ тәкъдим итте. Ул елны Корбан бәйрәме, Олы хаҗ җомга көнгә туры килде. Фарыз хаҗ җомгага туры килгәндә хаҗ кылучылар Хаҗиәкбәр булалар. Миңа шушы бик сирәкләргә, 10-12 елга бер генә туры килгән бәхет насыйп булды.

2000 һәм 2002 елларны изге җирләрдә әти-әнием өчен хаҗ кылдым. 2007 елны 75 яшь тулу хөрмәтенә, мәчет салуларда тырышканым өчен Татарстан мөфтияте җәмәгатем белән икебезгә хаҗга юллама бүләк итте.

Һәр хаҗымны Аллаһы Тәгаләнең бүләге, рәхмәте дип кабул иттем. Ул насыйп итмәсә, беркем дә берни эшли алмый. Күпме генә теләсә дә бара алмый. Согудиягә чикләр ачылуы, ике-өч сәгатьтә илтеп җиткерүче очкычлар уйлап табылуы, кешеләрнең сәфәрләрен җиңеләйткән уңайлыклар - барысы-барысы Аллаһы Тәгалә хозурлыклары, Аның кодрәте! Әгәр дә берәр кеше көнләшеп, кемнең күпме хаҗ кылуларын санап, тикшереп, гайбәтенә төшеп кала икән, ул кеше беркайчан да бу җирләргә аяк баса алмас. Күңел тарлыгы нәтиҗәсендә Аллаһы Тәгалә аның юлларын яба.

Олы гыйбадәтне үтәп кайтучылардан гадәттә тәэсирләрен, кичерешләрен сорашалар. Хаҗ - ул сүзләр белән аңлатып бетереп булмаслык гаҗәеп күңел халәте. Анда күңел чистара, җиңеләясең. Дөнья тормышың өчен гыйбрәтләнәсең. Кыямәт көне булачагына ышанып, шуны күзалларга да этәрә, уйландыра, тәүбә иттерә торган урын ул. Мәккәгә аяк басуга, Кәгъбәтулланы күрүгә хисләр өермәсенә чумасың. Барып урнашуга исәнләшү хаҗына - тәвафка ашыгасың бит инде. Карыйсың, Кәгъбәтулла тирәли бөтен халык намазлыгын җәеп намаз көтә. Үтә торган түгел, урамнар тулы. Шуларны күргәч, уйлыйсың: әллә Кыямәт көне җиткәнме. Бөтен әрвахлар үзләренең каберләреннән кубарылып, ак кәфенлекләрендә җир өстенә чыгып утырганнармы икән, Аллаһы Тәгалә хөкемен көтеп утыралармы икән дигән тәэсир туа. Икенче бер гыйбрәтле нәрсә: шайтанга таш атарга барасың. Шул вакытта юл кырыйларында хәер сораучы күпме гарип-гораба тезелешкәнен күрәсең. Бар да күзеңә карап, синнән ярдәм көтә. Кем кулсыз, кем аяксыз, бар кара тәнлесе, бар сары тәнлесе, бар кысык күзлесе... Күңелгә шундый чагыштыру килә: ахырзаман җитеп, хисап көне имеш. Бу гөнаһлы кешеләр миңа әз генә булса да әҗер-савабыңны бирче дип кулларын сузганнар... Үзеңне уйлыйсың, аның сәдака соравын онытасың, һәркем үзен кайгырта... Кәгъбәтуллага кергәндәге-чыккандагы тыгызлыклар мәхшәр мәйданын искә төшерә. Һәркем үз юлында, һәркайсы үз эшендә.

Сәфәр тәэсирләре хакында сорашучыларга менә шундый чагыштыруларымны вәгазь итеп сөйлим. Хаҗ - бу фани дөньябызда үзебезне ничек тотуыбызны уйлап тәүбәгә килү, Аллаһтан ярлыкауны сорау урыны. Шул ук вакытта ахирәтне күз алдына китерерлек күренешләр дә тулып ята. Үткәнеңне уйлыйсың, киләчәгең өчен кайгырасың. Иманың ныгый, Аллаһка якынаеп, тагын да шөкрана итәсең, гыйбадәттә утырып күп-күп догалар кыласың.

**Гыйльмулла хәзрәт ХӘЛИУЛЛИН,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы әгъзасы, Казанның Мәдинә мәчете имам-хатыйбы**

# ӘЛ-МАТУРИДИ ТӘГЪЛИМАТЫ ТАТАРЛАРГА НИЧЕК ҮТЕП КЕРГӘН?

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

дөньядан китеп баргач, вазгыять үзгәргән, Аллаһ ачышлары иңдерелү тукталган, мөселманнар Коръән һәм Сөннәттә булган олуг бу мирас белән бергә-бер торып калганнар.

Мөселманнарга Коръән белән Сөннәт кенә җитми идемени? Нишләп кисәк кенә бу фәннәр барлыкка килгән соң? Ни өчен гакыйдә, фикъһе, сира, тәфсир, хәдис, ысул әл-фикъһе, үлүм әл-Коръән, үлүм әл-хәдис һәм башкалар барлыкка килгәннәр? Бу үсеш-үзгәреш тарихта ничек барган соң?



**Алда әйтеп кителгән фәннәрнең барлыкка килүе берничә сәбәпкә бәйле. Менә аларның кайберләре:**

- *Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мирасын саклап калу зарурлыгы;*
- *Исламны гарәп булмаганнар арасында да тарату;*
- *Исламга таныш булмаган йогынтылар (идеологияләр), диннәр, йолалар, мәдәниятләр белән очрашырга туры килүе;*
- *аерым дин белгеченең шәхси сыйфатларының йогынтысы;*
- *Ислам эчендә төрле агымнар һәм мәзһәбләр барлыкка килү.*

Алга таба катлаулы тарихи бу процессны күзәтеп чыгыйк.

Системалаштыру, Ислам фәннәренең килеп чыгышы һәм барлыкка килү барышы, әлбәттә, Коръәннән башланып киткән. Билгеле булганча, Әбу Бәкер хакимлек иткән вакытта хәлифәттәге сәяси вазгыять тотрыксызлана. Бу - ялган пайгәмбәрләр килеп чыгу, кайбер кабиләләрнең зәкят түләүдән баш тартуы һәм кайберәүләрнең хәтта мөшриклеккә кире күчүләре аркасында килеп чыккан. Катлаулы бу вазгыять вакытында Әбу Бәкер барлык фетнәчеләр белән дә сугышырга карар иткән. Бу сугышлар вакытында беренчеләрдән булып Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) сәхабәләре шәһит киткән, алар араларында Коръән хафизлары да күп булган. Мәсәлән, Ямам орышы вакытында җитмешләп Коръән белгече һәлак булган. Бу Гомәр бине әл-Хәттабны сагаерга мәҗбүр иткән, һәм ул, Коръәнне язма рәвештә бер җыентыкка туплау кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыккан. Әбу Бәкер бу фикердән, мондый эш Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзе яшәгән вакытта да булмаганына сылтау ясап, башта бераз куркып калса да, Гомәр бине әл-Хәттабның ныклы үгетләве нәтиҗәсендә, аның белән килешкән. Нәтиҗәдә, Коръән тексты беренче тапкыр язма рәвештә бер җыентыкка тупланган.

Соңыннан, Госман бине Гаффан заманында, Коръәнне икенче тапкыр бер җыентыкка туплау үткәрелгән. Бу туплауның асылы шунда булган - ул укуның курәеш вариантында тупланган. Билгеле булганча, соңгы Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) заманында гарәп теленең җиде шивәсе (хәрф) булган. Һәм Аллаһы Тәгалә, Коръән барысына да аңлаешлы булсын өчен, аны алда әйтелгән шивәләрнең җидесендә дә иңдергән. Сәхабәләр, Коръәнне Пәйгамбәребездән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) алгач, аны үз шәкертләренә үзләре сөйләшкән шивәдә тапшырганнар. Госман бине Гаффан заманында сәхабәләрнең күп шәкертләре хәзерге Азәрбайҗан территориясенә җибәреләә торган гаскәрләрдә җыелган булганнар һәм алар арасында Коръәннне дөрес уку буенча каршылыклар килеп чыккан. Мөэминнәр арасында фетнә чыгу куркынычын сизеп, Хөзәйфә бине әл-Яман Мәдинәгә ашыккан, анда хәлифкә барып барысын да сөйләгән, аннан соң: "Өммәтеңә дөрес укуны күрсәт", - дигән. Нәтиҗәдә, Госман бине Гаффан Коръәнне бары тик курәеш шивәсендә генә саклап калырга карар иткән, ә башка сөйләшләрдәге бар язмаларны да юк итәргә фәрман бирелгән. Аннан соң Коръән язуларын камилләштерү дәвам иттерелгән, нокталар кертелгән, сузык авазларны билгеләүче тамгалар эшләнгән, соңыннан тәҗвид фәне барлыкка килгән.

Аннан соң Сөннәтне саклап калу буенча эшләр эшләнгән, хәдисләрнең беренче җыентыклары төзелгән. Хәдисләрнең беренче җыентыкларын сәхабәләр үзләре үк төзи башлаганнар. Араларында иң билгелеләре исә Габдулла бине Әмр бине әл-Ас һәм Гали бине Әбу Талиб җыентыклары. Ләкин бу юнәлештә системалы эш бары тик хәлиф Гомәр бине Габделгазиз фәрманыннан соң гына башланган. Алар арасында Бине Шиһаб әз-Зөһри, имам Мәлик, Әбу Мөхәммәд Габделмәлик бине Габделгазиз бине Җөрәйҗ, Әбу Әмр Габдрахман әл-Әүзаи, Әбу Абдулла Суфьян бине Сәед әс-Сәүри, Әбу Сәлем Хәммәд бине Сәлем бине Динар җыентыкларын аерып күрсәтергә кирәк. Әтулыландырылган хәдис җыентыклары бары тик һиҗри буенча III гасырда гына дөнья күргән.

I гасыр ахырына таба Ислам галимнәре арасында белгечлекләргә бүленү башлана. Беренче махсус хезмәт булып Бине Исхакның Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм тормышы турында язылган китабы исәпләнә. Кызганыч, ул үзенең төп нөсхә хәлендә безгә кадәр килеп җитмәгән, без аны Бине Хишам тасвирлавында гына алганбыз һәм бу хезмәт сира фәненең нигезе булып тора. Аннан соң әкренләп гакыйдә, фикъһе, ысул әл-фикъһе, тәфсир, тарих һ. б. фәннәр буенча да аерым хезмәтләр күренә башлый.

Гакыйдәгә тәфсилләп тукталып, бу фәннең үсешенә төрле мәзһәб белгечләре ярдәм итүен әйтеп китәргә кирәк. Беренче мәзһәбләр дүртенче хәлиф Гали (рг) вакытында күренә башлыйлар. Бу хариҗиләр һәм шигыйлар була. Башта алар сәяси хәрәкәтләр генә булсалар да, вакытлар үтү белән алар үз идеологияләрен дә булдыралар. Шуңа бәйле рәвештә, калган мөселман галимнәре алдында, бу мәзһәбләр идеяләрен кире кага торган дәлилләр эшләү мәсьәләсе килеп баса. Бу җәһәттән, аеруча мутәзиләләрне күрсәтеп китәргә кирәк. Мутәзиләләр үз тәгълиматларында юнән (грек) галимнәре хезмәтләреннән файдаланганнар. Аларның төп ялгышы - аңны Коръәннән һәм Сөннәттән өстенрәк дип санауда. Сөземтәдә, алар Коръәннең барлыкка китерелгән булуы, кабердә җәзага тартуның мөмкин түгеллеге, зур гөнаһлар кылучыны иманлы да, иманын җуйган дип тә танып булмавы һ. б. шуның кебек ялгыш нәтиҗәләргә килгәннәр. Һәм, әлбәттә, сөнничелек галимнәре мутәзиләләр идеологиясен кире кагарга мәҗбүр булганнар. Әгәр дә Әбу Хәнифә мутәзиләләр белән бары тик дини бәхәсләр (дискуссияләр) генә алып барса, Әхмәд бине Хәнбәл заманында вазгыять кискенләшкән. Моның сәбәбе - мутәзиләләрнең хакимияткә килүе була. Дәүләтнең мәҗбүр итү аппаратын кулланып, алар үз тәгълиматларын бар мөселман дөньясына тагарга тырышканнар. Ул чорның күп кенә галимнәре җәзага тартылган, төрмәләргә утыртылган, җәфа чигәргә мәҗбүр булган. Ләкин хәлиф алмашыну белән мутәзиләләр хакимиятләрен югалтканнар һәм сөнничелек галимнәренә Ислам дөньясын мутәзиләләр идеологиясеннән арындыру мөмкинлеге туган. Нәкъ менә шул чордан Әһле-Сөннәт вәл-Җәмәгать төшенчәсе барлыкка килү турында сөйли башларга мөмкин. Бу дәвердә Ислам гыйлемендә ике мәктәп булган: Әшарийә һәм Матуриди мәктәпләре. Беренчесе - Багдад галиме Әбу әл-Хәсән әл-Әшарига, икенчесе - Урта Азия дин белгече Әбу Мансур әл-Матуридига барып тоташа. Алар икесе дә Ислам тәгълиматын тәртипкә салганнар, ә алардан соң килгән бар галимнәр дә бу фән үсешенә зур өлеш керткәннәр. Әл-Әшари һәм әл-Матуриди хезмәтләре белән танышкан вакытта, аларның I гасыр Ислам галимнәре хезмәтләреннән (сәләф) әллә ни аерылып тормаганын күрергә мөмкин. Төрле тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә, әл-Әшари мәктәбе, күпчелектә, Ислам дөньясының көнбатышында, ә әл-Матуриди мәктәбе исә көнчыгыш өлешендә таралыш тапкан. Әл-Матуридиның дәвамчылары нигездә - хәнәфиләр, ә әл-Әшариныкылар калган өч мәзһәб вәкилләре.

Безнең Идел-Урал төбәгенә әл-Матуриди тәгълиматы, әлбәттә, Урта Азиядән үтеп кергән. Билгеле булганча, күпләр, башта болгарлар, ә аннан соң аларның нәселләре - татарлар, Бохара, Сәмәрканд, Кабул һәм башка шәһәрләр мәдрәсәләрендә белем ала торган булганнар. Аннан укып кайткач, алар мөгаллим булып китеп, үз шәкертләрен үзләре укыган программалар буенча укытканнар. Әбу Мансур әл-Матуридиның хезмәтләре шактый катлаулы дини телдә язылган, алар белән бары тик яхшы әзерлекле, гарәп телен камил белгән укучы гына шөгыльләнә ала.

**Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,**
**Татарстан мөфтие вазифаларын вакытлыча башкаручы, тарих фәннәре кандидаты**

# "Исән-сау кешенең һәр минуты, мизгеле бәхеткә төрелгән, күбесе аны аңламый, санламый гына"

**Мамадыш районының Иске Завод авылында Тәскирә апа һәм Минияз абый Гаяновлар гаиләсендә 1963 елның февралендә көтеп алган уллары Исмәгыйль дөньяга килә. Сау-сәламәт булып. Алты айдан аңа "чәчәк" авыруыннан прививка ясыйлар.**

Шушы прививкадан соң бала бик каты чирли, температурасы 41 гә күтәрелә һәм гарип кала. 1970 елны укырга керә ул. Яңа елга хәтле укый. "Балакаем, кабат укырга килеп йөрмә", - ди аңа пенсиягә китәргә бер ел вакыты калган, үз өстенә җаваплылык аласы килмәгән укытучысы. Ләкин малай 1971 елда кабат беренче класска укырга керә һәм тагын каршылыкка очрый. Куллары гарип булганлыктан, ямьсез, начар яза ул. Укытучысы дәфтәрен аркылы-торкылы сызып, ике-өч мәртәбә кайтарганнан соң, Исмәгыйльнең гайрәте чигә. Әнисе укытучының өенә барып: "Син язуының ямьсезлегенә карама, дөреслеген кара", - дип ачуланып кайта. Шуннан соң сигезенчене бетергәнче аңа бер укытучы да сүз әйтми. Кичке мәктәпкә йөреп, урта белем ала. 1981 елда Свердловск өлкәсенең Камышлов шәһәрендәге инвалидлар өчен училищега укырга кереп, аяк киеме тегүче һөнәренә өйрәнә. Бераздан Новочеркасск шәһәрендә техникум тәмамлап, аяк киемнәре тегү өчен дүртенче разрядлы техник-технолог белгечлеге дипломы ала. 1990 елда гаиләле булырга насыйп була аңа. Архангельск өлкәсендә яшәгәндә өйләнеп, җәмәгате белән биш ел гомер итә.



Ләкин язмыш егетне тагын сыный - хатыны үлеп китә. Аннары ул Мамадыш шәһәренә кайтып, көнкүреш йортында аяк киемнәре тегә. Әмма авыруы көчәю сәбәпле, эшеннән китәргә туры килә. Юллар аны туган авылына - әнисе янына илтә. Иске Завод авылында яхшы гына төзелеп ятканда мәчет төзелеше кинәт тукталып калган икән. Авыл аксакалы Каюм Әхмәтшин: "Балакаем, бар ышаныч синдә. Артыннан йөреп эшләтеп бетерсәң иде", - ди Исмәгыйльгә. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, авылдашлары белән мәчетне сафка бастыралар. Менә шуннан соң ул биш вакыт намазга баса. Хәзерге көндә Мәскәү-Уфа трассасының Рәхмәт мәчетендә имам-мөәзин вазифаларын башкара. Әле яңа гына ремонт ясаганнар: мәчетне утын ягуга көйләгәннәр. Менә шулай тулы канлы булып, сау-сәламәт кешеләр дә булдыра алмаган эшләрне башкарып йөри. Бу кешене мин күп еллар күзәтеп киләм. Ул мин яшәгән йортка апасы янына килә. Култык таягына таянган, үзе менә-менә егылып китәр кебек атынып тора. Аллага шөкер, нинди генә кайгы-хәсрәт килсә дә, нинди генә фаҗигаләргә генә юлыкса да, кешелеклелеген югалтмаган, мәрхәмәтлеген саклый белгән кеше ул. Моның хәтле сабырлык,түземлек каян киләдер аңа? "Яшьтән газап чигеп яшәсәм дә, Аллаһы Тәгаләгә зарланганым юк, - ди ул. - Әти-әниегез сүзенә колак салсагыз, гомер буе бәхетле яшәрсез. Исән-сау кешенең һәр минуты, мизгеле бәхеткә төрелгән, күбесе аны аңламый, санламый гына".

**Рәсемдә: Исмәгыйль хәзрәт.**

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш**

## Әбу Хәнифәнең хикмәтле сүзләре

***Тән әгъзалары күз белән идарә ителгән кебек, гамәлләр гыйлем белән билгеләнелә. Надан булып, күп эшләүгә караганда, белү һәм аз эшләү күп тапкыр файдалы. Бу - белмичә, чүлдә зур багаж белән өстерәлеп баруга караганда, кирәкле запасың булып, юлны белү яхшырак булган кебек.***

Мин гөнаһларның түбәнлек икәнен күреп алдым. Аларны кыю рәвештә калдырдым - һәм алар тәкъвалыкка әйләнде.

Аллаһ хәрам кылган нәрсәне эшләүне гыйлеме тыймаучы югалту кичерә.

Әгәр галимнәр Ахирәттә һәм фани дөньяда Аллаһ разый булган бәндәләр түгел икән, димәк, Аллаһның разый булган бәндәләре юк.

Әгәр дөнья мәсьәләсен хәл итәргә телисең икән, аны хәл итмичә торып, күп ашама, чөнки күп ашау акылны караңгылый.

Әгәр казый, белә торып, гаделсез хөкем итә икән, аның карарының көче булмый. Аны вазифасыннан төшерүләренә яки төшермәүләренә карамастан, ул үзенең бозыклыгы сәбәпле аннан читләштерелә.

Фикъһе турында сөйләшергә теләмәгән кеше белән бу турыда сөйләшмә, чөнки үзеңнең әңгәмәдәшеңә авырлык тудырачаксың. Син сөйләгәндә сине бүлдерүчегә әйткән сүзеңне кабатлама, чөнки ул гыйлемне аз ярата!

Дөнья өчен гыйлем алуга омтылучы, [белемне] йөрәгенә беркетмичә, үзенең бәрәкәтен югалта. Гыйлемне дин өчен өйрәнүче, аны йөрәгенә беркетеп, гыйлемдә күркәм була, гыйлеме белән башкаларга файда китерә.

**"Әбү-Хәнифәнең тормышы һәм мирасы" китабыннан алынды**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 6.10.12 | 5:27 | 6:57 | 13:02 | 16:24 | 18:05 | 19:35 |
| Якшәмбе | 7.10.12 | 5:29 | 6:59 | 13:02 | 16:23 | 18:03 | 19:33 |
| Дүшәмбе | 8.10.12 | 5:31 | 7:01 | 13:02 | 16:21 | 18:00 | 19:30 |
| Сишәмбе | 9.10.12 | 5:33 | 7:03 | 13:02 | 16:19 | 17:58 | 19:28 |
| Чәршәмбе | 10.10.12 | 5:35 | 7:05 | 13:02 | 16:17 | 17:55 | 19:25 |
| Пәнҗешәмбе | 11.10.12 | 5:37 | 7:07 | 13:02 | 16:16 | 17:53 | 19:23 |
| Җомга | 12.10.12 | 5:39 | 7:09 | 13:02 | 16:14 | 17:50 | 19:20 |
| Шимбә | 13.10.12 | 5:41 | 7:11 | 13:02 | 16:13 | 17:48 | 19:18 |




## Дин кушканча яшәргә телим, тик әйләнә-тирәмдәгеләр моны кабул итми...

СОРАУ-ҖАВАП

***Мин православие динендәгеләр яшәгән җирдә дөньяга килгәнмен. Шул сәбәпле, барлык туганнарым да, дусларым да православие динендә. Ә мин исә Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, Аның берлегенә һәм Мөхәммәднең (сгв) Гайсә пәйгамбәрдән соң килгән Илче булуына бернинди шикшөбһәсез ышанам. Әмма күңелемне берничә сорау кымырҗытып тора. Шуларны сезгә ирештерәсем килә.***

Беренчедән, чын хакыйкатькә ирешеп булырмы икән? Икенчедән, аңа бөтен кеше дә (барлык мөселманнар да) бертигез дәрәҗәдә омтылыш ясыймы? Бу турыда уйлап та карамаган кешеләр белән киләчәктә нәрсәләр булачак?

Әйе, мин гөнаһлы. Һәркөн гөнаһ кылам. Һәм һәрвакыт бу турыда исемнән чыгармыйм. Ә якыннарым вә дусларым исә гел бәхеттә "йөзә"ләр, үз-үзләрен азапламыйлар. Монысы бер хәл, миңа бит аларның хәмер эчемлекләр куллануы ошамый; туганнарым спиртлы эчемлекләргә Исламда мөнәсәбәтнең нинди булуын яхшы беләләр белүен... тик тормышларына "үзгәреш кертү" турында уйлап та караганнары юк. Ләкин мин аларны яратам һәм алар да мине яратмый түгел, яраталар шикелле. Тик миңа ислам дине кануннары буенча яшәве барыбер кыен. Һәм, һәрвакытта да, шәригать кануннарына сыймаган гамәлләр кылган чакта, мин моны яхшы аңлыйм. Аллаһы Тәгаләгә чын күңелемнән ышанам. Кызганыч, әлегә Ул кушканча яши алмыйм. Сез ни диярсез микән: минем белән Аллаһы Тәгалә идарә итәме, әллә шайтанмы? Сезнең киңәш-ярдәмегезгә бик тә өметләнеп калам.

*Исемемне, адресымны язмыйм*

**Сезнең соравыгызга Татарстанның көнчыгыш төбәге казые, Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов җавап бирә:**

- Әгәр дә сез Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең (сгв) Аның Илчесе булуына ышанып шәһадәт китергәнсез икән, сез мөселман булып саналасыз.

Гөнаһсыз кешеләр юк, пәйгамбәрләр генә гөнаһ кылмаганнар, чөнки аларны гөнаһ кылудан Аллаһы Тәгалә саклаган. Пәйгамбәребезгә (сгв) сәхабәләр: "Синең янында булганда иманнарыбыз бик тә куәтле була, әмма синең яныңнан киткәч, дөнья мәшәкатьләренә чумабыз һәм иманнарыбыз зәгыйфләнә", - дигәч, Мөхәммәд (сгв): "Әгәр дә сезнең иманыгыз һәрвакыт минем яндагы кебек булса, фәрештәләр сезгә кулларын биреп күрешерләр иде, әгәр сез гөнаһ кылмасагыз, Аллаһ сезне башка кавемнәр белән, гөнаһ кылганнан соң тәүбә итүчеләр белән алыштырыр иде", - дигән. Чөнки Аллаһы Тәгалә тәүбәләрне кабул итүче. Бәндәнең гөнаһ кылганнан соң тәүбә итеп Үзенә ялваруын сөя. Тәүбә итүнең өч шарты бар: гөнаһ кылудан туктау, үкенү һәм киләчәктә мондый гөнаһны кылмаска ниятләү (ныклы карар кылу).

Ислам дине кешеләрне, аларның нинди дин һәм милләттән булуларына карамастан, кешелекле мөнәсәбәттә булырга өнди. Башкача була да алмый, чөнки безнең динебез - барлык кешеләр өчен дә Аллаһы Тәгаләдән иңдерелгән хак дин. Шуңа күрә дусларыгыз белән яхшы мөнәсәбәттә булыгыз, чын дус булып калыгыз. Ягъни, динебез кушканча, аларны да хикмәт һәм яхшы вәгазь белән иманга, гомумән, тел белән генә түгел, үрнәк булырлык әдәп-әхлак, изгелек белән, яман гадәтләрне ташлап, яхшы якка гына үзгәреп, ата-ана, туган-тумача, күрше хакларын җиренә җиткереп үтәп чакырыгыз. Тик Раббыбыз тыйганны кылуда гына аларга ярдәм күрсәтмәгез һәм буйсынмагыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) бер хәдисендә: "Аллаһы Тәгалә кануннарына каршы булган эшләрдә һичкемгә буйсыну юк", - ди.

Шулай ук гөнаһ кылучыга булышлык күрсәтү дә гөнаһ санала, мәсәлән, хәмер эчемлекләрне кулланучылар белән бер өстәл артында утыру.

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 14 (157) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9419.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 4 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**